РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕФРОЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ФРОЛОВО
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

15.06.2020 — № 6

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 февралендәге 14 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегендә муниципаль заказ һәм вәкаләтле орган һәм муниципаль заказчыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында нигезләмәгә» үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 февралендәге 14 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегендә муниципаль заказ һәм вәкаләтле орган һәм муниципаль заказчыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында нигезләмәгә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба- Нигезләмә):

- Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.5 пунктының 13 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм расларга: «алты йөз мең сумнан артмаган суммага товар, эш яки хезмәт күрсәтүне сатып алу турында закон таләпләре нигезендә карар кабул итәләр һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу реестрын алып баралар;».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы Зур Фролово
авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе — О.Г. Масленцева